| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br><br>**СОВЕТ ЯНУРУСОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br><br>**САРМАН**<br><br>**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**<br><br>**ЯНУРЫС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**<br><br>**СОВЕТЫ** |

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**22.11.2024** **№13**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында «Федераль законның 16 статьясына үзгәреш кертү хакында» 30.09.2024 елгы 338-ФЗ номерлы Федераль законның 1 абзацы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 08.08.2024 елгы 232-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Сарман муниципаль районының «Янурыс авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы белән Янурыс авыл җирлеге Советы карар чыгарды.

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җирлеге Советының 2022 елның 14 февралендәге 34 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәреш кертергә:

1) 6.3 пункты. түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“6.3. Җирле үзидарә органы җитәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, җирле үзидарә органы җитәкчесе урынбасары, мәнфәгатьләр конфликтын бетерү максатларында, алар тиешле вазыйфаны биләгән чорда әлеге җирле үзидарә органының сайланулы профсоюз органында муниципаль хезмәткәрләр мәнфәгатьләрен яклый алмый.”;

2) 9.3 пунктның 5 пунктчасында «һәм квалификация турында»сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми

муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Янурыс авыл җирлеге
Советы рәисе А.Ә.Мөхәмәдиева